РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 14 » 08 2023 г. №1204

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 20 декабрендәге 1052 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә 2022 елга муниципаль торак контроле буенча саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» Федераль законның 2 һәм 3 статьяларына һәм Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 18.03.2023ел, 71 номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 20 декабрендәге 1052 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә 2022 елга муниципаль торак контроле буенча закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программаның 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Муниципаль контроль предметы булып Россия Федерациясенең торак законнарында, энергияне сак тоту турындагы һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турындагы законнарда, муниципаль торак фондына карата газ белән тәэмин итү турындагы законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар һәм гражданнар (алга таба - контрольдә тотыла торган затлар) тарафыннан үтәлүе тора»;

1.2. Программаның 1.2 пунктын түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

«12) йорт эчендәге һәм (яисә) фатир эчендәге газ җиһазларын имин эксплуатацияләүгә һәм аларга техник хезмәт күрсәтүгә таләпләр, шулай ук күпфатирлы йортта вентиляция һәм төтен каналларын тотуга карата таләпләр.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында урнаштырырга .

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина